ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш); 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми:»;

2) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:
«$2^1$) күпфатирлы йортларда һәм (яисә) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында (рестораннардан тыш) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр;»;

3) 3 пунктның беренче абзацында «гомуми мәйданы» сүзләреннән соң «, килүчеләргә хезмәт күрсәтүнең сезонлы залы (зонасы) мәйданын исәпкә алмыйча,» сүзләрен өстәргә;

4) 4 пунктта «гомуми мәйданы» сүзләреннән соң «, килүчеләргә хезмәт күрсәтүнең сезонлы залы (зонасы) мәйданын исәпкә алмыйча,» сүзләрен өстәргә;

5) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сату бары тик рестораннар, барлар, кафелар, буфетлар кебек җәмәгать туклануы объектларында гына, шул исәптән күпфатирлы йортларда һәм (яисә) аларга якын территорияләрдә урнашканнарында да, гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка срогы билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2 һәм 5 пунктлары 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2024 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 59-ТРЗ